ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.11.2021 г. Заинск № 680

**«Зәй муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турында» 2018 елның 29 июнендәге 1089 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

«Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 29 октябрендәге 1021 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

## карар бирә:

1. «Зәй муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турында» 2018 елның 29 июнендәге 1089 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган (2018 елның 17 декабрендәге 1864 номерлы, 2019 елның 22 мартындагы 151 номерлы, 2019 елның 17 декабрендәге 646 номерлы, 2019 елның 20 декабрендәге 648 номерлы, 2020 елның 10 июнендәге 247 номерлы, 2020 елның 10 июлендәге 298 номерлы, 2021 елның 14 октябрендәге 617 номерлы карарлар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) Зәй муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турында нигезләмәгә үзгәреш кертергә, 2 нче таблицаның 1, 2 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «1. | Авыл җирендә һәм шәһәр тибындагы бистәләрдә урнашкан рус телле булмаган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында | педагогик хезмәткәрләрнең вазыйфалары | өченче – дүртенче | 5,0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | балаларны рус теленә өйрәтү | | | |
| 2. | Рус телле мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны туган телгә (татар, чуаш, мари һәм башка телләргә (рус теленнән тыш) өйрәтү | педагогик хезмәткәрләрнең вазыйфалары | өченче – дүртенче | 5,0». |

2. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сәфәргалиев
3-27-42